КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 8 июнь г.Казань № 361

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25 июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 656 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.1.108 – 4.1.109 пунктчалар өстәргә:

«4.1.108. Инвестицион программалары Татарстан Республики башкарма хакимият органнары тарафыннанраслана һәм тикшерүдә тотыла торган субъектлар исәбенә кертелгән электр энергетикасы субъектларының инвестицион программаларын раслый, шулай ук әлеге инвестицион программаларны тормышка ашыруны тикшерүдә тота.

4.1.109. Инвестицион программалары федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан раслана һәм тикшерүдә тотыла торган субъектлар исәбенә кертелгән территориаль челтәр оешмаларының инвестицион программаларын килештерә, шулай ук әлеге инвестицион программаларны тормышка ашыруны тикшерүдә тотуда катнаша.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\361.docx